**ГЛАВА ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,, с.Куркачи , ул. Клубная , 4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы, Клуб ур.,4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:.Ikaz.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«23» октября 2024 г.** **№11**

## Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Татар Әйшәсе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 21 октябрьдәге 167 номерлы карары нигезендә 2019 ел (19.05.2020 ел редакциясендә) 187)» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында " Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

Карар кылды:

Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Татар Әйшәсе авылында үзара салым кертү буенча 2024 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын уткэру

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Татар Әйшәсе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;
- урамнарны яктырту җайланмасы.

"КАРШЫ" РИЗА

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://vysokaya-gora.tatarsta№ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

Иске Казан авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Закирова